КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2024 ел, 28 ноябрь г.Казань № 1074

Татарстан Республикасы бюджетыннан бирелә торган субсидияләрне алучыларны сайлап алу башкарыла торган дәүләт мәгълүмат системалары турында

Россия Федерациясе Бюджет кодексының 785 статьясындагы 5 пункты нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Түбәндәгеләр дип билгеләргә:

Россия Федерациясе Бюджет кодексының 785 статьясындагы 1 пунктында күрсәтелгән субсидияләр Татарстан Республикасы бюджетыннан бирелгәндә субсидияләр алучыларны сайлап алу «Электрон бюджет» иҗтимагый финанслар белән идарә итүнең дәүләт интеграцияләнгән мәгълүмат системасында яисә «Минем субсидияләр» дәүләт мәгълүмат системасында гамәлгә ашырыла;

әлеге пунктның икенче абзацында күрсәтелгән субсидияләр алучыларны сайлап алу гамәлгә ашырыла торган дәүләт мәгълүмат системасы Россия Федерациясе бюджет законнары нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының субсидияләр бирүне җайга сала торган норматив хокукый актлары белән билгеләнә.

2. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин